Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Берлек-Михайловка авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

7 ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 7 ноябрендә узган: «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

Октябрина торак пункты чикләрендәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (юл өслеген күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре).

Октябрина торак пунктында су алу өчен пирс әзерләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 35 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 22 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 22 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Берлек-Михайловка авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

Октябрина торак пункты чикләрендәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (юл өслеген күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре) буенча кабул ителгән карарны танырга;

.

Октябрина торак пунктында су алу өчен пирс әзерләү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)  буенча кабул ителгән карарны танырга;

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы: О.В.Охотникова